**Республика Татарстан**
**Рыбно-Слободский**
**муниципальный район**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Кугарчинского сельского поселения**
**422662, с.Кугарчино.**
**ул.Советская , дом 62 а**

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе**
**муниципаль районы**
**Кугэрчен авыл җирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**422662, Кугәрчен авылы.**
**Совет урамы, 62 а йорт**

**тел:8(84361)28-5-89, факс :8(84361)28-5-89** **эл .почта** Kugar.Rs@tatar.ru

**сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

29.01.2021 Кугәрчен авылы №1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегендә җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм "Җирләү һәм мәет кую эше турында" 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 маддәсендәге 3 пунктын, 12 маддәсендәге 3 пунктын, "Татарстан Республикасында җирләү һәм мәет кую эше турында" Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карарының 3 пунктын үтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Пенсия фондының 2021 елның 13 гыйнварындагы "2021 елның 1 февраленнән Россия Пенсия фонды тарафыннан гамәлгә ашырыла торган индексацияләү турында"гы СЧ-25-24/270 номерлы хатына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1, 2 нче кушымталар нигезендә 6424,98 сум күләмендә билгеләргә һәм 2021 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча күрсәтелә торган

хезмәтләрнең хакын раслау турында" 2020 елның 31 гыйнварындагы 2 номерлы карарын 2021 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Күгәрчен авылы, Совет урамы, 62А йорт; адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күгәрчен авыл җирлеге башлыгы А.Т.Сафин

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Күгәрчен авыл
җирлеге Башкарма
комитетының 2021 елның 29
гыйнварындагы
1 номерлы карарына
кушымта №1

**Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегендә
2021 елның 1 февраленнән җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең
гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган
хезмәтләрнең бәясе (хакы)**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 1966 |
| 3. Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка (крематорийга) күчерү (алып бару) | 975 |
| 4. Җирләү (мәетне яндыру, соңыннан көле салынган урнаны бирү белән) | 3483,98 |
| Җәмгысе: | 6424,98 |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Күгәрчен авыл
җирлеге Башкарма
комитетының 2021 елның 29
гыйнварындагы
1 номерлы карарына
кушымта №2

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегендә ире (хатыны), якын туганнары, бүтән туганнары яисә мәрхүмнең законлы вәкиле булмаганда яки алар тарафыннан мәет куюны гамәлгә ашыру мөмкин булмаганда яисә җирләү бурычын үз өстенә ала торган башка зат булмаганда, мәет кую буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча түләүсез нигездә (бушлай) күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе (хакы)**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 542 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 1424 |
| 4. Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка күчерү (алып бару) | 975 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3483,98 |
| Җәмгысе: | 6424,98 |